**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре №216-31 2018елның «12» ноябреннән

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2009 елның 15 апрелендәге 274-37 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль хокукый актларны Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законнарына туры китерү сәбәпле,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Азнакай район Советының 2009 елның 15 апрелендәге 274-37 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында» нигезләмә;

Азнакай район Советының 2009 елның 15 апрелендәге 274-37 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында» нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында» 2009 елның 29 октябрендәге 303-41 номерлы карары.

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин